Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге
Советы КАРАРЫ

27№ 2014 елның 19 ноябре

## ФИЗИК ЗАТЛАР МИЛКЕНӘ САЛЫМ ТУРЫНДА

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2014 елның 30 октябрендәге "Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәй датасын билгеләү турында 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Карата авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге Советы территориясендә физик затлар милкенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) 0,1 процент: гараж һәм машина урыннары;

һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче, дача хуҗалыгы, яшелчә бакчасы, бакчачылык яки индивидуаль торак төзү өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелешләре;

2) 0,2 процент: фатирлар;

бүлмәләр;

3) 0,3 процент: торак йортлар;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак урыны (торак йорт) булса да керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент:

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китүче салым салу объектлары;

5) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

**3. Үз көчен югалткан дип танырга:**

Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи авыл җирлеге Советының

2010 елның 16 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2010 елның 16 октябрендәге 7 номерлы карарын;

4. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Түбән Кәчи авыл җирлеге рәисе Елифанов М.И.